

12 нче февраль коне безнен гаилә очен зур бәйрәм. Чонки 1923нче елнын февралендә туган минем әбиемә, Зәкия Арибжановна Аюповага, уникесендә 95 яшь тулды. Бала чагы авыр елларга туры килә.Чәчәк аткан чакларында, рәхәтләнеп яшәргә генә дигәндә, Боек Ватан сугышы башлана. Илебезнен һәрбер гаиләсенә тошкән кайгы-хәсрәт әбиемнен дә оенә килә. Авылыбыздагы ир–ат беренче коннән ук фронтка китә, ботен авырлыклар хатын-кыз иннәренә тошә. Колхозда трактористлар калмагач, аларны алмаштырыр очен яшь кызларны укырга жибәрергә уйлыйлар.Әбием vз теләге белән, Ләмберәдә оештырылган трактористлар әзерләv курсларында беренче июльдән беренче августка кадәр укый. Укып бетергәч, тракторга утырып, колхоз жирләрен сорә башлый. 1943 нче елда фронттан яраланып (конфузияләнеп) кайткан сойгән ярына, Мигажетдин Юнус улы Аюповка, киявгә чыга. Гаиләдә бер-бер артлы балалар туа башлый. Авыр сугыш еллары...Черегән бәрәнге боламыгыннан пешерелгән коймакларны, кычыткан белән алабутаны да туйганчы ашамаганнар. Ләкин кешелелекне югалтмаганнар, шәфкатьле булганнар. Халкыбыз бик кvп кыенлыклар кvрсә дә, бер-берсенә ярдәм итеп, дус булып, якын туганнар кебек яшәгән.Тиздән жинv коне житәр дип омет иткәннәр. Еллар vтә... Тугыз баланы аяк остенә бастырып, һәрберен укытып, кайсын ойләндереп, кайсын кияvгә бирепә, оныклар vстереп, рәхәтләнеп яшә дигәндә генә, бабакай vлеп китә. Яраткан кешенне югалту бик авыр инде. Кайгы ялгыз йорми дип юкка әйтмиләр.Туып-vстергән баланны югалту тагын да авыр. Бер-бер артлы әбиемнен оч улы Равил, Рәшит, Рәстәм vлләр. Аннары олы оныгы Дамир яшьли вафат була.

Алла Тагәлә әбиемә тагын сынаулар бирә: ин кече баласы Ринат та vлеп китә. Шундый кайгы-хәсрәтләр кичергән әбиемнен рухы сынмады. Балалары, оныклары, оныкларынын оланнары һәрвакыт янында яшәп, хормәтлиләр, кадерлиләр, яраталар, бvгенге конгә әниләреннән, әбиләреннән кинәш сорыйлар, сvзен тынлыйлар. Балалары гына тvгел, тирә-кvрше дә, авыл халкы да хормәтли. Мин еш уйлыйм: карт конендә шундый хормәт кvpv очен, ничек сон доньяда гомер итәргә кирәк? Минемчә, әбиемнен бер дә усаллыгы булмаган, һәрвакыт халыкка ярдәм итеп, булышып, изге теләкләр теләп, яхшы эшләр эшләп яшәгән; кешене рәнжетмәгән, кеше алдамаган, кешенекен алмаган; туган жирендә тырышып хезмәт иткән.

Мин Зәкия әбием белән бик тату торам. Әбием белән донья, тормыш турында, анын язмышы турында сойләргә яратам. Әбием мина: «Оныгым Риана, минем яныма килеп

ешрак сойләш, чонки син Ринат улымны хәтерләтәсен. Синен белән сойләшкәч күнелемә тыныч, рәхәт була. Кызым, бик тә әтиенә охшыйсын. Тагын, син генә бит минем хыялымны тормышка ашырдын. Син хәзер укытучы. Мин дә яшь чагымда укытучы булырга бик теләгән идем, ләкин мәктәпне бетергәндә әтием үлеп китте. Шулай итеп, хыялланып кына калдым. Аннары сугыш башланды... Әй кызым, синен укытучы булуынны күрү очен генә дә мина Раббым Алла шундый озын гомер биргән дип уйлыйм», - ди Зәкия әбием.

Минем әбием бик бай: тугыз бала анасы, 18 оныгы, 29 оныкларынын баласы, тагын бер оныгынын оныгы- оныкчыгы. Әбием, яшенә карамастан, тулы зиһендә, ул һәрберебезнен туган коннәрен белә һәм тәбрик итә, һәммәбезгә бүләк тә бирә. Әбиемнен теләкләре һәммәбезгә бер үк: «Балаларым, гомерегездә сугыш һәм ачлык күрмәгез, арагызда дошманлык булмасын, чын кешеләр булыгыз, саулык белән яшәгез».

Кадерле әнкәебез, әбиебез, синен доньяда барлыгын очен, тәрбиян очен бик зур-зур рәхмәт сина!

Ә бүген безнен зур гаиләбез газиз әнкәебезне, әбиебез Зәкия Арибжановны туган коне белән котлый. Саулык, бәхет, шатлык, тынычлык телибез. Якты күк йозендә кояш нурлары жылытып торсын сине, ал таннар коч китерсен, кайгы-хәсрәтләр килмәсен, жил-давыллар булмасын.

Хөрмәт белән оныгын Риана АЮПОВА

P.S. Пензятка мәктәбе коллективы кайнар котлап изге теләкләр тели Зәкия Арибжановна Аюповага. Ул мәктәпне ярата һәм булган чараларда рәхәтләнеп катнашып килде. Киләчәктә бәхетле картлык телибез!